Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге
Иске Иглай торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«21» ноябрь 2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2022 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Иске Иглай торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Иске Иглай торак пунктында урамнарны яктыртуны оештыру һәм карап тоту:

- Иске Иглай торак пунктында суүткәрү системасын төзү һәм эчә торган су белән тәэмин итү

Халык җыенында рәислек итүче: Р.И. Фәйзуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Фәйзуллин